**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Чыбыклы авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 134** **27.09.2024г.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 28.10.2022 73 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең ерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Чыбыклы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авылҗирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 28.10.2022 № 73 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.4.6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«4.6.4. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлешеһәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.»;

1.2. 4.7.10 пунктынтүбәндәгередакциядәбәянитәргә:

«4.7.10. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.»;

1.3. 4.9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«4.9.5.Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында"(PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында"Авыл җирлекләре" бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Чыбыклы авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н. Гадершин